РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

30.01.2023 ел №164

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм район чикләрендә җирлекләр арасында транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм район чикләрендә җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә, Кармыш, Лашман, Түбән Кәминкә, Түбән Кармалка, Яңа Элмәле, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре башкарма комитетларына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына:

- Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә, Кармыш, Лашман, Түбән Кәминкә, Түбән Кармалка, Яңа Элмәле, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Чирмешән, Шешминка авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында кушымта нигезендә типлаштырылган форма нигезендә килешү төзергә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында районның Финанс-бюджет палатасына бюджет законнары нигезендә эшләргә һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы

бюджеты турында» 2022 елның 9 декабрендәге 148 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының каравына тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының икътисадый сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы
Башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары Г.М. Җамалтдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2023 елның
30 гыйнварындагы 164 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан _________________авыл җирлеге башкарма комитетына халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм район чикләрендә җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**
**килешү**

**Чирмешән авылы** **«____»________2023 ел**

Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты, алга таба «район Башкарма комитеты» дип аталучы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Җамалетдинов Илнур Минсәгыйт улы йөзендә бер яктан, Устав нигезендә гамәл кылучы һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы __________ авыл җирлеге башкарма комитеты, алга таба «Җирлек башкарма комитеты» дип аталучы, _________ авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе_________ __ йөзендә, Устав нигезендә гамәл кылучы икенче яктан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү район Башкарма комитеты тарафыннан _______ авыл җирлеге башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыруны беркетә.

1.2. Район башкарма комитеты җирлекнең башкарма комитетына халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм район чикләрендәге җирлекләр арасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыра.

2. Акчалар күләмен билгеләү тәртибе

2.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан Чирмешән муниципаль районы _________ авыл җирлеге бюджетына ________________ күләмдә бирелә торган акчалар исәбеннән башкарыла.

2.2. Чирмешән муниципаль районы бюджетыннан Чирмешән муниципаль районы _________ авыл җирлеге бюджетына әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бирелә торган акчаларны

формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 3. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Җирлек башкарма комитеты әлеге килешүнең 1 бүлеге һәм гамәлдәге законнар нигезендә район Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.2. Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында Яклар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актларында каралган срокларда һәм күләмнәрдә мәгълүмат алмашырга йөкләмә бирәләр.

3.3. Район Башкарма комитеты җирлек башкарма комитетына тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен һәм вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тота.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, нигезе һәм туктатылу тәртибе

4.1. Әлеге Килешү 2023 елның 1 гыйнварыннан алып _______________ кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.2. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

4.2.1. Яклар килешүе буенча.

4.2.2. Берьяклы тәртиптә:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаса, шул исәптән Россия Федерациясе һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары үзгәргән очракта да;
- икенче якка 1 ай алдан хәбәр итү шарты белән район Башкарма комитеты инициативасы буенча, җирлек Башкарма комитеты тарафыннан үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармау (яки үтәмәү), субвенцияне максатчан кулланмау фактын билгеләгән очракта.

4.3. Килешүне өзү язма формада рәсмиләштерелә.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәү өчен җаваплы.

5.2. Җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармау фактын билгеләү әлеге килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора. Туктату турында килешүне имзалаудан соң яки Килешүне туктату турында язма хәбәр алганнан соң 30 көн эчендә килешүне өзү, документаль рәвештә расланган фактик чыгымнарны алып калып күчерелгән субвенцияләрне кире кайтаруга китерә.

5.3. Җирлек башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә гамәлгә ашыру өчен җаваплы.

5.4. Әлеге Килешүдә каралмаган якларның җаваплылык чаралары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган гражданлык законнары нормалары

нигезендә кулланыла.

## 6. Башка мәсьәләләр

6.1. Якларның үзара ризалыгы буенча яки гамәлдәге законнар таләпләренә туры китереп, әлеге Килешүгә язма рәвештә үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертелергә мөмкин, алар Яклар кул куйганнан бирле әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә килеп чыккан, Яклар белән җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

6.3. Әлеге килешү тигез юридик көчкә ия 3 (өч) нөсхәдә, һәр Якка берәр нөсхәдә һәм Районның финанс-бюджет палатасына бер нөсхәдә төзелде.

## 7. Якларның адреслары һәм башка мәгълүматлар

| «Район Башкарма комитеты» | «Җирлек башкарма комитеты» |
| --- | --- |
| Муниципаль район Башкарма комитеты ___________ | Авыл җирлеге башкарма комитеты ___________ |
| _____________________ _______________ <br>(имза) (ФИАт.ис.) | _____________________ _______________ <br>(имза) (ФИАт.ис.) |

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов

Район Башкарма комитеты
җитәкчесенең икътисад
мәсьәләләре буенча урынбасары С.Н. Кузнецова

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары И.И. Кәримов